**ГЛАВА**
**Терсинского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Тирсә авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.10.2020 Тирсә авылы № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Чишмә авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тирсә авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тирсә авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының « Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Чишмә торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 13 ноябрендә 14 сәг 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Чишмә торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Чишмә авылы территориясендә урам юлларын тоту.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Чишмә ав., Центральная ур., 4 нче йорт янында үткәрергә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тирсә авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru).

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Р.Р. ЗАКИРОВ